МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11 август 2017 ел № М 327

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешнең 3 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында нигезләмәне кушымтада каралганча расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары Ф.И. Андреевага, Башкарма комитет Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллинга, Контроль-хисап палатасы Рәисе Т.В. Шливега йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Хакименең
2017 елның 11 августындагы
М 327 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан бер генә кеше идарә итә торган
башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар
(сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга
яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә эшкә алучы
(эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында
нигезләмә

1. Әлеге Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешнең 3 пункты нигезендә эшләнде һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык, яшелчәчелек, дача куллану кооперативы күчемсез милек хуҗалары ширкәте белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга (алга таба – муниципаль хезмәткәрләрнең коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуы) эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу процедурасын регламентлаштыра.

2. Муниципаль хезмәткәрләрнең коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуы мәнфәгатьләр конфликтына яки мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлегенә китерергә тиеш түгел.

3. Коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәте турында гариза (алга таба – гариза), әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында каралган форма буенча, җирле үзидарә органы җитәкчесе исеменә язма рәвештә муниципаль хезмәткәр тарафыннан төзелә.

4. Муниципаль хезмәткәрләр гаризаны җирле үзидарә органының кадрлар хезмәтенә (кадрлар эше буенча белгечкә) (алга таба – кадрлар хезмәте) бирәләр.

5. Гаризаны теркәү, әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасында каралган форма буенча, Бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт турында гаризаларны теркәү журналы (алга таба – Теркәү журналы), кадрлар хезмәте тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Теркәү журналының битләре номерланган, шнурланган һәм кадрлар хезмәте яки җирле үзидарә органы мөһере белән расланган булырга тиеш.

6. Билгеләнгән тәртиптә теркәлгән гаризаның күчермәсе кадрлар хезмәте

тарафыннан муниципаль хезмәткәрнең кулына бирелә яисә алу турында белдерү кәгазе белән почта аша җибәрелә. Муниципаль хезмәткәргә тапшырылырга тиешле гаризаның күчермәсенә, гаризаны теркәү датасын һәм номерын, әлеге гаризаны теркәгән вазыйфаи затның фамилиясен, инициалларын һәм вазыйфасын күрсәтеп, «Гариза теркәлгән» тамгасы куела.

7. Кадрлар хезмәте, муниципаль хезмәткәр түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашкан очракта, мәнфәгатьләр конфликты булу яки мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлеге предметына кергән гаризаны карап тикшерә һәм дәлилләнгән бәяләмә әзерли.

8. Муниципаль хезмәткәр түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашканда мәнфәгатьләр конфликты яки мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлеге ачыкланган очракта, кадрлар хезмәте дәлилләнгән бәяләмәдә муниципаль хезмәткәр гаризасын канәгатьләндерүдән баш тарту турында күрсәтә.

9. Муниципаль хезмәткәрнең гаризасы һәм дәлилләнгән бәяләмә, гариза теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә кадрлар хезмәте тарафыннан җирле үзидарә органы җитәкчесенә җибәрелә.

10. Җирле үзидарә органы җитәкчесе, биш эш көне эчендә, гаризаны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча карар чыгара, муниципаль хезмәткәр гаризасын канәгатьләндерә яки әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында күрсәтелгән кадрлар хезмәте бәяләмәсендә бәян ителгән нигезләр булганда, муниципаль хезмәткәр гаризасын канәгатьләндерүдән баш тарта.

11. Кадрлар хезмәте, гаризаны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан карар кабул ителгән вакыттан башлап биш эш көне эчендә, муниципаль хезмәткәргә кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

12. Гаризаның төп нөсхәсе һәм аны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарның күчермәсе муниципаль хезмәткәрнең шәхси делосына теркәлә.

Муниципаль берәмлек
башлыгы урынбасары

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КЕГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Ф.И. Андреева

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

үрнәк

________________________________________

________________________________________

җирле үзидарә органы җитәкчесенең вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары

________________________________________

________________________________________

муниципаль хезмәткәр вазыйфасының исеме, фамилиясе, исеме һәм атасының исеме

Бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт турында
гариза

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ санлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 бүлекнең 3 пункты нигезендә, миңа бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуны, коллегиаль идарә органнары составына керүне рөхсәт итүегезне сорыйм (кирәк булмаганын сызарга яки бетерергә)

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________.

(коммерцияле булмаган оешма турында, муниципаль хезмәткәр башкарырга ниятләнгән эшчәнлек турында мәгълүматларны, кем буларак, тиешле эшчәнлекне башкара башлауның күздә тотылган датасын, башкаларны күрсәтергә)

____________________

____________________

(дата) (имза)

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

үрнәк

Бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт турында гаризаларны теркәү журналы

| № | Гариза биргән муниципаль хезмәткәрнең Ф.И.А.и. | Гариза биргән муниципаль хезмәткәрнең вазыйфасы | Кадрлар хезмәтенә гариза керү датасы | Гаризаны кабул иткән муниципаль хезмәткәрнең Ф.И.А.и. | Гаризаны кабул иткән муниципаль хезмәткәрнең имзасы | Гаризаның күчермәсен алганда муниципаль хезмәткәрнең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |